

25 мартта Мордовия Республикасы Матбугат үзәгендә хокук тәртибе гаскәрләре оешуга 215 ел тулуга һәм Росгвардиягә 10 ел тулуга багышланган брифинг узды. Росгвардиянен Мордовия Республикасы буенча идарә житәкчесе, полиция генерал-майоры Андрей Каринкин СМИ хезмәткәрләренә эшчәнлегенен топ юнәлешләре турында сойләде. Беренче чиратта ул Росгвардия бүлекчәләренен топ хезмәт бурычлары турында әйтте. Тобәктәге ведомствонын остенлекле бурычлары арасында хокук тәртибен һәм гражданнарнын иминлеген тәэмин итү, террорчылыкка һәм экстремизмга каршы корәш, шулай ук гадәттән тыш һәм хәрби хәл режимын саклап калуны аталды. Моннан тыш, Росгвардия корал әйләнеше һәм шәхси сак эшчәнлеге олкәсендә федераль дәүләт контролен гамәлгә ашыра, шулай ук торле билгеләнештәге объектларны саклау белән шогыльләнә.
Росгвардиянен РМ буенча идарәсе бүгенге кондә полициянен махсус бүлекчәләренен ике отрядын үз эченә ала: «Аркуда» - махсус билгеләнештәге мобиль отряд һәм «Звезда» - тиз жавап бирүче махсус отряд. Алар хокук саклау органнары тарафыннан махсус чаралар уздырганда коч кулланып ярдәм итәләр. Ведомстводан тыш сак, лицензия-рохсәт бирү эше һәм дәүләт контроле бүлекчәләре, шулай ук идарә органнары белән бергә барлык структуралар Росгвардия идарәсенен республикадагы актуаль хезмәт кон тәртибен формалаштыралар.
«Хәзерге вакытта шәхси составнын гомуми саны меннән артык кеше тәшкил итә. Корал, хәрби-махсус техника һәм матди чаралар белән комплектланганлык бүгенге кондә 97% ка житә. Сонгы елларда без бу юнәлештә шактый алга киттек, комплектлашу арта гына бара», - дип хәбәр итте Росгвардиянен РМ буенча идарәсе житәкчесе.
2025 елда СОБР бүлекчәләре, Росгвардия тобәк идарәсе хезмәткәрләре һәм хәрби хезмәткәрләре махсус хәрби операция - СВО уздыру кысаларында бурычларны үтәү очен Россия Федерациясенен дүрт чик буе субъекты территориясендә 20 тапкыр командировкага чыкканнар. Анда Росгвардия хезмәткәрләре халыкнын иминлеген, хәрби хәлнен хокукый режимын һәм контртеррористик операцияне үтәүне булдыра, азат ителгән территорияләрдә неонацист формированиеләренә каршы корәш алып бара. Росгвардиячеләрнен, СВО зонасында хокук саклау органнарыннан коллегалары һәм гаскәр группировкалары житәкчелеге морәжәгатьләре буенча эшләү, махсус һәм фильтрацион чаралар белән тәэмин итү, халык белән эвакуация чаралары үткәрү, шартлау куркынычы булган предметларны эзләү, табу, идентификацияләү, зарарсызландыру һәм юк итү кебек моһим бурычлары да бар.
Андрей Каринкин пилотсыз очу аппаратларына каршы торуга һәм моһим инфраструктура объектларын саклауга аерым тукталды: «Безнен идарәдә ОМОН составында инженер-техник группа бүлекчәсе бар. Ул БПЛАга каршы тору, торле корал һәм шартлаткыч жайланмаларны зарарсызландыру очен барлык кирәкле чаралар белән жиһазландырылган.»
Росгвардиячеләр кон саен жәмәгать тәртибен саклау буенча хезмәт итәләр. Быел Мордовиядә Росгвардия хезмәткәрләре тарафыннан полиция бүлекләренә торле хокук

бозулар кылган 60тан артык граждан китерелгән. Республикабызда лицензия-рохсәт бирv эше һәм дәvләт контроле бvлекчәсе 25 мен берәмлек корал әйләнешен, контроль-кvзәтчелек чараларын гамәлгә ашыра. Узган елда, Росгвардия бvлекчәләре катнашында, 10 берәмлек корал, 1000 данәдән артык торле калибрлы сугыш кирәк-яраклары, 7 кг артык шартлаткыч матдә тартып алынган (изьято). Мордовия халкы, Росгвардиянен актив катнашында, СВО зонасындагы сугышчыларыбызга пилотсыз очу аппаратлары һәм дроннар белән корәшv очен 350 берәмлек граждан коралы тапшырган.
Йомгаклап, генерал-майор Андрей Каринкин Росгвардиянен Мордовия Республикасы буенча идарәсе куелган бурычларны тулысынча vти, дип ышандырды. Ул шәхси составын, хокук саклау блогы буенча хезмәттәшләрен һәм Мордовиядә яшәvчеләрне бәйрәмнәр белән котлап иминлек, нык сәламәтлек, унышлар теләде.

**Наилә НАСЫРОВА**